КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 17 апрель

г.Казань

№ 433

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәткәндә клиникада файдалану өчен медицина оешмаларын донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 август, 590 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын тормышка ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәткәндә клиникада файдалану өчен медицина оешмаларын донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 август, 590 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 сентябрь, 883 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм идарәсенә йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре програм-

масын тормышка ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәткәндә клиникада файдалану өчен медицина оешмаларын донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү тәртибенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Медицина оешмаларын донор каны һәм (яисә) аның компонентлары белән тәэмин итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Донор канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортлау һәм клиникада файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 14 маендагы 641 номерлы карары белән расланган Донор канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортлау һәм клиникада файдалану кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин